СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

22 МАРТ, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 32 (8044) | Бәясе билгеләнгәнчә.

*Авыл: Кичә. Бүген. Иртәгә.*

## СЕМИНАРДАН КАЙТТЫЛАР

**Бу атнада Әлмәт районында агропромышленность комплексында кардиналь реформалар үткәрү, бер үк вакытта авыл эшчәннәре алдында торган җаваплы эш - язгы кыр эшләре кампаниясен оешкан төстә үткәрү буенча алда торган көнүзәк бурычларны тикшерүгә багышланган ике көнлек республика семинар - киңәшмәсе булды. Анда район хакимияте башлыгы җитәкчелегендә безнең районның да күп кенә хуҗалык, агропромышленность комплексына мөнәсәбәтле кайбер ведомстволар җитәкчеләре катнашты.**

**Семинар - киңәшмәдә катнашучылар башта районның берничә хуҗалыгында булып авыл хуҗалыгында структур реформалар үткәрү тәҗрибәсе белән таныштылар, авылда хезмәтне нәтиҗәлерәк итү максатыннан киң кулланылышка тәкъдим ителә торган яңа төр техникалар күргәзмәсен карадылар. Күргәзмәгә безнең Норлат машина төзү заводында эшләгән яңа төр культиваторлар да куелган иде.**

**Семинар киңәшмәнең пленар өлешендә республика Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министры В.П.Васильев республика агропромышленность комплексында эшләрнең бүгенге торышына җентекле анализ ясады, икътисадый һәм финанс кыенлыклары шартларында алга таба хезмәтне ничек нәтиҗәле оештыру мөмкинлекләре турында сөйләде.**

**Семинар - киңәшмә эшенә йомгакны Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев ясады. Аның чыгышыннан ачык аңлашылганча, республикада агропромышленность комплексында тотрыклылыкны тәэмин итү, продукция җитештерүнең уңай нәтиҗәле булуына ирешү өчен әлегә юл бер генә - кайсы гына тармакта да җиргә һәм башка материаль байлыкларга чын хуҗа булдыру, шул юл белән авыл кешесенең үз хезмәтенең нәтиҗәлегеге өчен җаваплылыгын үстерү, аның кайсы гына продукцияне дә җитештерүнең чыгымнарны мөмкин кадәр киметергә мөмкинлек бирә торган юлларын табып куллануына ирешү. Ә инде бу максаттан крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциацияләре эчендә структур реформалар уздыру, шул исәптән кооперативлар һәм башка төр берләшмәләр төзүнең формаларының кайсысы максатка ярашлырак дип табыла, урыннарда шунысын сайларга кирәк. Ничек кенә булса да, моннан ары искечә яшәп һәм эшләп кенә мантып булмаячагы көн кебек ачык.**

**Шунысы куанычлы, безнең районда бу юнәлештә киң колачлы эш җәелеп килә инде: крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциацияләрендә реформаларның төрле формалары кертелә һәм моннан ары ул эшнең масштабы тагын да киңәячәк әле.**

## ТЕЛӘК БАР, НӘТИҖӘ БУЛЫР

«40 лет Победы» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе хуҗалык итүнең яңа, отышлы формасын кулланырга теләп байтактан эзләнүләр алып бара. Кыш көне барлык белгечләр белән Азнакай районына барып, алдынгы саналган «Авангард» кооперативында булып, аларның эше белән җентекләп танышып кайтулары да шул максаттан булды. Инде узган шимбәдә ассоциация эшчәннәре, ниһаять, үз язмышларына җитди үзгәреш кертергә тиешле бу мәсьәлә турында уртага салып сөйләшергә, бердәм булып иң кулай юлны сайларга дип җыелышка килделәр. Шунысын әйтергә кирәк: чулпанлылар бу сөйләшүгә бик җитди, оптимистларча карадылар һәм үзләрендә әлеге үзгәрешне уңышлы гамәлгә ашырып, ныклы икътисадка ирешеп яшәү өчен көч - сәләт җитәрлек дип санийлар. Алар күп формалардан үзләренә ярашлы дип күмәк кооперативлар формасын сайладылар. Хуҗалыкны 4 кооперативка бүлделәр. Алар - катнаш җитештерү - терлекчелек һәм игенчелек белән дә шөгыльләнәчәкләр, берсе - хезмәт күрсәтүчеләрдән тупланачак. Соңгысына баш белгечләр, хисап эшчеләре, мастерскойдагы токарь, эретеп - ябыштыручы кебек хезмәт күрсәтүчеләр керәчәк. Алдагы звеноларның икесе кырчылыкта бөртек, берсе азык җитештерү белән мәшгуль булачак. Шул специфikадан чыгып техника, гадел итеп җирләр бүленде, терлекчелек абзарлары, маллар беркетелде. Һәр кооперативта 870әр гектар җир исәпләнә, аларны кооператив даими кулланачак. Кырларны болай беркетү киләчәктә кооперативларның җирнең уңдырышлылыгын күтәрү, аларны ашлау, басу юлларын тәртипкә китерү белән даими шөгыльләнүгә кызыксындырачак. Билгеле, хуҗалык итүдә ахыр нәтиҗәгә эшләү, үзара чек системасы буенча исәп - хисап ясау да шуңа - авыл эшчәннәренең активлыгын, хуҗаларча мөнәсәбәтен күтәрүгә юнәлтелгән, чөнки аз чыгымнар тотып мул продукция җитештерү шунсыз мөмкин түгел.

Җыелышта яңа шартларда беренче язны каршылап, кыр эшләрен уңышлы үткәрү өчен зур тырышлык соралачагына басым ясалды. Быел «40 лет Победы»да басуларга кертү өчен 806 тонна физик авырлыкта ашлама тупланды, ул тәэсир итүчән матдә исәбеннән һәр гектарга 136 кг. дигән сүз. Хәзер биредә тракторларга ремонт эшләре бара.

Авыл эшчәннәре бар тырышлыкларын киләчәкләре хакына хезмәткә бирергә, авылны таратмыйча - таркатмыйча заманча рәвеш белән нык, мул тотрыклы тормышка ирешергә дигән теләк белән таралыштылар. Ә теләк нык булганда, эш башкарылырга тиеш.

**С.НУРУЛЛИНА.**

*Мәгариф*

## Икесе дә тигез булсын

Ике теллелекне гамәлгә ашыру. Район мәгариф бүлеге хезмәткәрләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән үткәрелгән бер генә чарасы да шул мәсьәләгә кагылмый калмый. Узган пәнҗешәмбедә рус мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучылар белән үткәрелгән киңәшмәдә дә сүз нигездә шул хакта барды. Киләсе уку елында шәһәр мәктәпләрендә балаларның рус телен һәм әдәбиятын тигез дәрәҗәдә өйрәнә башлаулары ике теллелек программасын гамәли тормышка ашыруга бер адым булачагы ассызыкланды. Шунда ук мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты укытуга бәйле башка проблемалар, аерым алганда күптән түгел республика татар теле һәм әдәбияты олимпиадасы нәтиҗәләре турында да эшлекле сөйләшүләр булды.

## *ТЕАТР ДЕКАДАСЫ*

Халыкара театр көне уңаеннан районыбызда театр ункөнлеге үткәрелә. Декада кысаларында узачак күптөрле чаралар арасында аеруча мөһимнәре:

Норлатта район мәдәният йортында:

**25 мартта** ***Фирзәр Мортазин*** концерты. Башлана - 20 сәгатьтә.

**26 мартта** Галимҗан Ибраһимовның ***«Татар хатыны ниләр күрми»*** әсәре буенча Бикүле татар халык театры спектакле.

Башлана 19 сәгать 30 минутта.

**27 мартта** Чистай татар халык музыкаль драма һәм комедия театрының ***«Хатын түгел, аждаһа»*** комедиясе (Д.Салихов әсәре).

Башлана 20 сәгатьтә.

**28 мартта** Норлат татар халык яшьләр театрының Юныс Әминов пьесасы буенча ***«Кошның үз канаты була»*** спектакле.

Башлана 19 сәгать 30 минутта.

**Спектакльләргә рәхим итегез!**

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

## БЕР АТНА КАЛЫП БАРГАНДА

**Татарстан Дәүләт Советына 50 нче Октябрь территориаль - сайлау округыннан кандидат - халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе, хакимият башлыгы Фатих Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИН.**

Сайлаучыларның кайсыннан гына сорама, районда бу сайлауга әзерлекнең гомер булмаганча бик тыныч үтүен әйтер. Һәм бу сайлау бюллетененә бары бер генә кандидат кертелүдән һәм кандидатның районда иң зур урындагы кеше булуыннан түгел. Хикмәт, мөгаен моңарчы кандидатның сүзе эштән аерылмавындадыр. Ә безнең сайлаучылар кандидатларның вәгъдәләрен һәм реаль эш - гамәлләрен чагыштырып карарга өйрәнде инде. Дала Мамыгыннан Норлатка суүткәргеч сузу, Каравыл Тавы янында Чирмешен аша яңа күпер салу, аэропорт төзү, газлаштыру темпының тизләтелүе, элеккеге автобус маршрутларын яңарту һәм яңаларын ачу, пенсияләрне һәм бюджеттагыларга хезмәт хакын вакытында бирә башлау, авыл хуҗалыгына профессиональ игътибарның көчәюе һәм инде шуның уңай нәтиҗәсе дә булу - болар барчасы сайлаучыларга бу сайлауда ничек тавыш бирергә икәнлеген хәзердән үк анык билгеләргә мөмкинлек бирде инде. Ә бездә һәр сайлаучы читтән бернинди басымга да буйсынмыйча, бары үзе теләгәнчә, намусы кушканча гына яшерен тавыш бирергә хокуклы - анысы Законда ныгытылган.

Бу көннәрдә безнең редакциягә сайлаучылардан Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидатка мөнәсәбәтләрен белдергән күп хатлар килә. Хатларның барчасында да кандидат турында уңай гына фикерләр очрый. Халык уңай үзгәрешләргә куана һәм хәлнең алга таба тагын да яхшыраачагына өметләнүләрен яшерми. Без аларны көндәлек почтадан алып, башка хатлар белән беррәттән газетага бирәбез. Менә бүген дә шундый хат бар. Шунысы да бар, сайлаучылар район җитәкчелеге күп кенә өлгергән социаль мәсьәләләргә алга таба бүгенгедән дә күбрәк игътибар итсен иде дип телиләр. Ф.С.Сибагатуллин үзе 14 мартта район мәдәният йортында булган очрашуда ясаган чыгышында андый шикләнүләргә урын калдырмаслык иттереп: «30 марттан соң да эшне дәвам итәчәкбез һәм кешеләргә мәшәкатьләрен хәл итүдә булышлык күрсәтәчәкбез» диде.

Сайлаучыларның барысының да, кечкенә генә авыллардагыларының да алар белән очрашуга депутатлыкка кандидатның ышанычлылары яки булышлык төркеме вәкилләре генә түгел, ә үзе килүен теләүләре аңлашыла, билгеле. Әмма хакимият башлыгының эше бик тыгыз шул, зур районның күпсанлы һәм колачлы проблемаларын хәл итү буенча ул якшәмбеләрне дә онытып иртәдән кичкә кадәр эштә.

Ә округ сайлау комиссиясендә бүген эш ничегрәк бара соң? «Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлау турында»гы Законда округ территориясендә сайлауларга әзерлекне оештыру, участок сайлау комиссияләренең эшенә җитәкчелек итү, тавыш бирү нәтиҗәләренә йомгак ясау - болар барысы аңа йөкләнгән бит.

**(Ахыры 2 нче биттә).**

## Бердәм булыйк

Сайлау көне якынлашкан саен безнең кандидатыбыз Фатих Сәүбән улы Сибагатуллинның Татарстан Дәүләт Советы депутаты булып сайланачагына ышанычым артканнан арта бара. Соңгы берничә айда гына да районда булган зур уңай үзгәрешләр дәлил моңа.

Пенсия түләүдә тәртип салынганлыкка сөенечтән яшь аралаш рәхмәт укыган күпме карт - карчыкны үз күзләрем белән күрдем. Икътисадыбыз шундый катлаулы чакта бу эштә тәртип салу Фатих Сәүбәновичка бер дә җиңел булмагандыр дип уйлыйм. Әмма биргән сүзендә тору дигән нәрсә аның тормыш кагыйдәсе бугай. Шуңа күрә бу сайлауларның нәтиҗәсе дә һичшиксез аның файдасына булачагына шикләнмим.

Тик тавыш бирергә генә мөмкин кадәр күбрәк кеше килсен иде дип кенә телим. Шуңа күрә сайлаучыларның яшен - картын 30 мартта сайлау участокларына бердәм булып килергә чакырам.

**Х.ӘХМӘТОВ.**
Норлат шәһәре

## 30 март - Татарстан Дәүләт Советына депутат сайлау көне

# БЕР АТНА КАЛЫП БАРГАНДА

( Ахыры.Башы 1 нче биттә).

**• Районда сайлауга 55 сайлау участогы әзерләнә.**

**• Сайлаучылар исемлегенә әлегә 39500 кеше кертелгән.**

**Н.Х.АБДУЛЛИН,**

**округ сайлау комиссиясе рәисе:**

- Бу сайлаулар безнең өчен аеруча җаваплы. (Әле соңгы биш айда гына да район Советына киткән депутатлар урынына ике сайлау уздырылган, тагын берсе майга билгеләнгән). Комиссиядә 11 кеше. Состав нигездә тәҗрибәле. Билгеләнгән чараларның барысын да законда каралган срокларда һәм тәртиптә уздырабыз. 30 мартта тавыш бирү иртәнге сәгать 7 дән кичке сәгать 9га кадәр барачак. Әгәр дә сайлаучы, кая да булса китәргә туры килеп, сайлау көнне монда була алмый икән, безнең комиссиягә, ә сайлауга ике көн кала участок сайлау комиссиясенә килеп алдан тавыш биреп куя ала. Андый чакта да тавыш бирүнең яшеренлеге тәэмин ителергә тиеш.

Һәр сайлаучы үзе өчен үзе генә тавыш бирә. Тик сайлау бюллетенен кулыгызга алгач, аның арткы ягында комиссия членнарының икесенең имзасы яки мөһер булу - булмавын карагыз. Әгәр авыру сәбәпле сайлау участогына килә алмыйсыз икән, участок комиссиясенә телдән яки язмача мөрәҗәгать итсәгез, комиссия членнары сезнең өегезгә киләчәкләр.

**- Нәбиулла Хәйруллович, бу кампаниядә мәгълүмлелеккә өмет итәргә мөмкинме? Югыйсә, әле кайчан гына моңа юл ябык иде бит...**

Комиссия утырышларында һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен санаган вакытта эш һәм тору урыннарында сайлаучылар җыелышында сайланган вәкилләр, шулай ук профсоюз һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша алалар. Тик аларның вәкаләтләре тиешенчә расланган булырга һәм алар 30 мартта участокларда торырга яки округ комиссиясе утырышында катнашырга теләүләре хакында 29 марттан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиешләр. Ул таләпләр ТР Законының 8 нче маддәсендә язылган.

**- Агитация кампаниясе кайчан тәмамлана? тәгәлләнә?**

- Ул сайлау көнне туктатыла. Сайлау участогы бүлмәсендә агитация алып барырга ярамавын да искәртәсем килә. Бу басма агитация материалларын тавыш бирү буласы бүлмәләргә, җәмәгать транспортына элүгә дә кагыла.

**Округ сайлау комиссиясеннән менә шундый мәгълүматлар бирделәр безгә. Н.Х.Абдуллин әйткәнчә, комиссиядә эшлеклелек. Моңарчы күп сыналган Октябрь районы сайлаучылары инде 30 мартта да үзләренең хак сүзләрен аңлы рәвештә әйтерләр дип ышанырга гына кирәк.**

**Т.НАЗАРОВА.**

# Керемнәрегез зурмы?..

**Физик затларның еллык керемнәре турында декларация тапшыру вакыты көннән - көн азая: 31 нче марттан соң билгеләнгән вакыт чыгачак. РФ законы буенча безнең илдә бары тик төп хезмәт урыны булган һәм шул чорда төп хезмәтеннән тыш керем алган, шулай ук төп хезмәт урыны булмыйча, башка чыганаклардан еллык кереме 12 миллион сумнан арткан физик затлар тапшыра. Бу мәҗбүри чарадан бары тик ел дәвамында төп эш урыннарыннан гына (теләсә нинди күләмдә) хезмәт хакы алучылар һәм шулай ук берничә предприятиедә эшләгәннән кергән тулай керем 12 миллионнан артмаган очракта азат ителәләр.**

**Бу җәһәттән хокук нормалары түбәндәгеләрне дә раслый: алынган керемнәрнең суммасына бәйсез рәвештә эшмәкәрлек эшчәнлеге, күчемле һәм күчемсез мөлкәтне арендага биреп торудан... һәм башкалардан кергән керемнәр хакында да гражданнар салым инспекциясенә хәбәр итәргә тиеш. Шулай ук хезмәт хакын натуралата түләү очракларында да гражданнар декларация тапшырудан азат ителмиләр.**

# Салым инспекциясенә ашыгыгыз!

Декларация бирелергә тиешле керемнең минималь суммасы 1996 елда 12 миллион, бу алдагы елдагы елдан нәкъ 2 миллионга артыграк. Бу сумма арткан саен салым да прогрессия буенча үсә.

| Хезмәт хакы | Салым күләме (процентларда) |
|---|---|
| 12.000.000 сумга кадәр | 12 процент |
| 12.000.001 сумнан 24.000.000га | 1.440.000 сум + 12.000.000нан арткан сумманың 20 проценты |
| 24.000.001 сумнан 36.000.000га | 3.840.000 сум + 24.000.000нан арткан сумманың 25 проценты |
| 36.000.001 сумнан 48.000.000га | 6.840.000 сум + 36.000.000нан арткан сумманың 30 проценты |
| 48.000.001 сумнан һәм аннан югары | 10.440.000 сум + 48.000.000нан арткан сумманың 35 проценты |

Күргәнегезчә, салым суммасы кечкенә түгел. Аңлашыла ки, гражданнарның салым инспекциясе белән исәп - хисапны өзәргә ашыкмаулары гаҗәп тә түгел. Ләкин билгеләнгән вакытка сыешмау җәзасыз калмый: **керемнәре турында декларацияне салым инспекциясенә үзвакытында тапшырмаган яки декларациядә дөрес булмаган мәгълүматлар китергән гражданнар икедән алып биш минималь хезмәт хакы күләмендә штрафка тартылалар,-** диелә законда. Минималь хезмәт хакы Россиядә әлегә 83490 сум, димәк, 166920 дән 417450 сумга кадәрле штраф керемнән алына торган сумма белән чагыштырганда әлләни куркыныч та түгел үзе. Тик шунысы бар, район салым инспекциясе начальнигы Г.В.Миннегалиев әйтүенчә, зур керемле гражданнарның декларация китермичә йөреп вакытны сузулары берничек тә алар файдасына түгел: салымнан котылу юлы юк, берничә тапкыр чакыртылып та декларация китермәүче гражданнарның эше салым полициясенә тапшырыла, ә ул исә суд ашамы, башкачамы тиешле сумманы түләтмичә калмый, хәтта җинаять җаваплылыгына тартылу куркынычы да яный.

Салым инспекциясе мәгълүматларына караганда, безнең районда 1995 ел өчен 165 декларация тапшырылган, тагын тапшырырга тиешле 56 кеше һаман да салым инспекциясе белән очрашуны суза килә икән. Кызыксынучылар өчен 165 гражданның 133сенең кереме 10.000.000 нан 20.000.000га кадәр, 18е - 21дән 30га, икесе 31дән 40ка, 4 се 41дән 50гә һәм 8 кешенеке 50.000.000нан артык исәпләнә. 165 - Нурлат өчен бу сан башка районнар белән чагыштырганда аз түгел, диләр инспекциядә, быел да шуннан ким булмаячак дип уйлыйлар. «Гомуми керемнәрен күрсәтеп декларация тапшыручы һәркемне салым көтә дигән сүз түгел әле. Документлар тапшырылганнан соң мәгълүматлар тикшерелә, ел агымында салынган салымнар исәпләнә, льготаларга хокуклар карала һәм шуннан соң гына керемнән салым алыну - алынмавы ачыклана. Шуңа да мәгълүмсезлек аркасында декларация тапшырудан шүрләп яту урынсыз да булуы мөмкин»,- ди физик шәхесләргә салым салу бүлеге начальнигы Т.С.Муракаева.

Салымнан котылып калу исәбе белән гражданнар нинди генә әйләнгеч юлларга, хәйләгә бармыйлар икән. Я берәр урында эшләп хезмәт хакын башка кеше паспорты белән алалар, гомумән берничә паспортны эшкә җигүчеләр бар (паспорт күбрәк булган саен хезмәт хакы азрак, димәк, салым да шулай ук). Элеккеге система буенча берничә кешелек бригадада барлык хезмәт хакын бер кеше - бригадир алу очраклары да әле һаман юк түгел. Нәтиҗәдә зыяны әлеге кешегә төшә - салым бер үзенә салына. Шундый аңлашылмаучылык килеп чыкмасын өчен, гражданнарга гомумән декларация хакында мәгълүматлы булу комачауламас, диләр салым инспекциясе хезмәткәрләре.

Шулай итеп, декларация тапшыруга саналулы көннәр калды. Бүгенгә әле декларация китерүчеләр чагыштырмача аз: бары тик бишенче дистәгә генә чыккан. Салым инспекциясе гражданнарга тоткарлыклар тудырмау йөзеннән шимбә көннәрендә дә эшләргә булуын хәбәр итә, һәм бу гамәлне соңга калдырмаска өнди: кайсы гына милек предприятиесендә эшләсәгез дә сезнең керемнәр хакында мәгълүматлар безнең игътибар үзәгендә диләр алар. Кем шикләнә, алдан шалтыратып карагыз: **телефоннар: 2 - 10 - 59, 2 - 22 - 09. Зур керемле гражданнар, сезне Октябрь районы салым инспекциясендә көтәләр.**

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

## *Исәннәргә кирәк бу*

## Михаил Горшенин

# ЯШЕЛ ҮЗӘН

Мамыктан Чистай юлына чыккач элекке Биләр ягына борылып керсәң, ике яклап урман чолгап алган аланлыкка килеп чыгасың. Бер биш чакрымнар узгач, Алтынка дип йөртелә торган кечерәк чокыр аша салынган җыйнак кына күпер булыр. Картлар, элек бу урыннардан узган бер сәүдәгәрне юлбасарлар сагалап торып юк иткәннәр, дип сөйлиләр иде. Ә теге мескеннең янында акчасы да бер «алтын» - ягъни өч кенә тиен булган. Өч тиен өчен җаны белән хушлашкан булып чыга теге һәм шуннан бирле чокыр «Алтынка» дип йөртелә дә. Ә Алтынкадан Зүзәйгә якын гына.

Зүзәй - кечерәк кенә поселок. Бирелә «Зеленый дол» дигән колхоз булган. Эш дигәндә халык бик тешләк, бердәм була анда, шуңа күрә корылык, боз сугу, көчле яңгыр яву, каты салкыннар кебек табигать бәла - казалары да, зур салымнар салып һәм продукциясен арзанга алган дәүләт тә, партиянең «зирәк» җитәкчелеге дә (авылда уполномоченныйлар бетеп тормый) - берсе дә бу күмәк хуҗалыкны җимерә алмый. Елның - елында әйбәт уңыш алалар, фермадан тиресне чокырга түгел, ә кырга түгәләр. Көтүчеләр малларны ач тотмыйлар, атлар да карап - сокланып туймаслык.

Мамык сабантуе әле дә күз алдында. «Тәрнәс» һәм «Мюд» совхозларының юртаклары зурлар, зифалар. Күп акча түләп еректан кайтартканнар диделәр. Һәм Зүзәйнең «Капля» дигән тәбәнәк кенә алмачуар аты алар арасында күзең дә төшәрлек түгел. Менә атлар чабарга тотынды. Теге «кыйммәтлеләр» оча гына инде, ә Зүзәйнеке өсдертеп кенә барган төсле. Тик... бөтен халыкның гаҗәпләнүенә каршы, ул тегеләрне куып та җитте, бөтенесен узып баш та килде. Шул минутта мәйдандагы халыкның ничек гөж килүен күрсәгез икән сез! Бөтен кеше аягүрә басты, кулларын болгый - болгый кычкыра, баскан урыннарында сикерә - коридадагы испаннардан бер дә ким түгел. Шулай булмыйча соң - колхозның бәләкәй генә аты совхозның гәүдәле юртакларын узды бит.

... Урман эчендәге чишмә буенда колхозның умарталыгы бар иде. Балны колхозчыларга хезмәт көненә дә өләшә торганнар иде ул заманнарда...

Тик шундый хуҗалыкны да таркатырдай көч табылды шул. Н.С.Хрущев вак хуҗалыклар рентабельсез, эре колхоз - совхозларның гына киләчәге бар дигән фикер белдерде дә, яшел үзәнлеләрне амбарында бер уч ашлыгы да булмаган эре колхозга китереп куштылар.

1949 - 50 елларда шул поселокта эшләдем мин. Шунда бер хатын - кызның тарихын ишеттем, шуны сезгә дә сөйләп бирәсем килә. Үземнең дә күргәнем булды аны. Гап - гади рус хатыны. Буйга уртача, таза тәнле, пөхтә киенгән, йөзгә чибәр генә. Тик аның карашында ниндидер бер серлелек бар иде. Йөзендә ниндидер оялчанлык, хәсрәт бар иде аның. Сиксәненче еллар уртасында Зүзәйгә барып чыккач ул хатынны күреп сөйләшергә теләгән идем, әмма аны инде күптән бу якты дөньяда юк диделәр.

(Ахыры 4 нче биттә).

## Республикабызда

Ниһаять, пенсионерлар пенсияләрен, ә бюджет системасында эшләүчеләр - укытучылар, медицина, мәдәният хезмәткәрләре хезмәт хакларын үз вакытында, айныкын - айга алып барачаклар. Күптән көтелгән бу шатлыклы хәбәрне әле күптән түгел генә билгеләнгән финанс министры Рөстәм Миннеханов шушы көннәрдә республиканың Министрлар Кабинеты Президиумы утырышында әйтте. Бирсен Ходай!

***

Мәскәүдә яңа татар газетасының тәүге саны дөнья күрде. Аның беренче битендә Мәскәүдә оешкан «Ак Барс» иҗтимагый татар берлеге дипломын алган «Салават» ансамбле рәсеме төшерелгән. Хәзер газета исеменә конкурс бара.

## Исәннәргә кирәк бу

# АНА ХӘСРӘТЕ

( Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Сугыш башлануга, ирен һәм улларын сыкранып фронтка озата һәм кызлары белән генә кала ул. Өендә дә бөтенесенә өлгерә, колхоз эшендә дә мактаулы була. Ә үзе көн туса фронттан хат - хәбәрләр көтә. Килә башта хатлар. Андый минутларында аның сөенүенә чик - чама булмый. Тик... «Хатлары ярты ай буе килгән бит, хәзер исәнме икән соң ул кадерлеләрем» дигән уйлар тынгылык бирми аңа. Дөрес, хатларда ананың күңелен күтәрерлек нәрсәләр язалар сугыштагылар. Әнә кече улының хаты. Өйне, сеңелләрен сагынуын әйткән, әнисеннән үзен саклавын үтенгән, яңа Т - 34 танкына утыруын язган, әйбәт экипаж туры килде, командирыбыз бик кыю, «исән булсак, үлмәбез, егетләр» дип күңелләрне күтәрә, дигән. Аннары: «Эх, ничек тә туйга кадәр яшисе иде» дип өстәгән. Ана кеше дә улына кушылып: «Ходай гына насыйп итсен иде инде, улым» дип пышылдый.

Тик авылга бер - бер артлы кара мөһер сугылган хатлар килеп тора шул... Әнә Настяның ире үлү хәбәре килде, биш ятиме белән калды ахирәте. Авыл буенча үкереп елап йөрмәсә дә, йөзе караңгы, көчкә генә йөри...

Ана көн туса фронттан хат көтә, тик кайгылы хәбәр кенә килә күрмәгәе дип курка. Ә 1943 елның җәендә хатлар да килүдән туктады: хат ташучы озын сыйраклы Нюрка: «Юк» кына ди дә, тизрәк читкә борылып китү ягын карый. Күңеле сизә ананың - җүнлегә түгел бу. Ә инде бер кичтә өенә колхоз рәисе килеп кереп, пилоткасын салып түргә, өстәл янына барып утыргач, ананың йөрәге кысылып куйды, шым калган балалары да аңа килеп сарылдылар. Барысын да аңлады ул шул минутта.

Председатель озак кына сүзсез утырды, йортны, кызларны күздән кичерде дә, карашын аңа төбәп: «Чыда инде, Анакай, ничек тә - улың һәлак булган, Ватан өчен һәлак булган»,- диде. -Безнең колхозга егерме җиденче хәбәр бит инде бу. Чалгы белән чапкандай кыра бу сугыш ирләрне. Минем Андреемнан да өченче ай инде хәбәр юк. Түз, Анакай. Андый - мондый нәрсә кирәк булса, әйт, булышырбыз. Утын, салам алып кайтырга кирәксә ат бирербез. Ничек тә түз, Анакай». Аннан ике генә бармаклы уң кулы белән кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарып өстәлгә куйды. Сул кулы белән гимнастерка кесәсеннән бөкләнгән газета чыгарып, тәмәке төреп кабызды...

Ана кешегә председательнең сүзләре җир астыннан килгән төсле ишетелде. Тамагы кипте, тыны кысылды, авызын ачып бер сүз әйтерлек хәле юк иде. Күз аллары караңгыланды, балаларының аңа чытырдап ябышуын гына тоярлык хәлдә иде ул.

Рәис, челемен тартып бетерде дә, пилоткасын каешына кыстырып, тагын бер кат балаларны күздән кичерде. Күз алдында сулыгып калган, яшькә чумган ана председательне чоланга кадәр озата чыкты. «Әле ярый ачыргаланып үкерми» дип уйлап куйды рәис эчтән генә...

Ә кыш көне бу йортка җилкәләрендә танк эмблемалы, йөзе көйгән яшь бер солдат килеп керде. Бүреген кулына тотып, баскан урынында таптанып торды да: «Трудолюбоводан мин, Анакай, госпитальдән чыккач бер атнага өйгә җибәрделәр, менә хәлегезне белеп чыгыйм дидем. Улыгыз белән бергә идек без, экипажларыбыз гына башка иде. Бик дуслар идек, шуңа да сезгә кереп чыкмыйча китә алмадым. Бу Катядыр инде»,- диде солдат кызларның кечкенәсенә күрсәтеп.

«Кара әле, нәрсә дип каккан казык кебек калдым соң әле мин, әйдә, сал өстеңне, улым, уз».- Ана солдатка үзе дә сизмәстән, улым -дип эндәште. - Әйдә, өстәл янына утыр, салма, салма аягыңнан, мин хәзер, улым, үт, әйдә үт...»

Җәһәт кенә табын әзерләде, идән астыннан чиреге белән көмешкә алып менеп, стакан тутырып салды да: «Эч улым, кабып куй» диде.

Солдат өзек - өзек итеп булса да җентекләп сөйләде. Ана аңламаган сүзләрне аңлатып бирде. Курск дугасында сугышканнар икән. Меңләгән танклар булган анда. Өсләренә самолеттан бомба яудырганнар. Маңгайга - маңгай килгән танкларның люкларын каерып ачарлык булмый торган иде, шуңа күрә кувалда белән ачарга туры килә иде дип сөйли... Ут - төтен эчендәге танктан кем чыкканын да чамаларлык булмый...

Улының ничек үлүе турында сүзе соңрак булды. Танкларны ромб рәвешендә тезеп атакага барганнар. Берзаман карыйм - боларның танкы туктады һәм ут - төтен эчендә калды, ди. Без алга таба киттек. Озак та үтми безгә дә тидерделәр. Атылып чыктык. Үзебезгә дә ут капты. Әле ярый янда гына елга бар иде, суга чумып кына исән кала алдык. Соңыннан гына белдем - сезнекеләрнең экипажы янып үлгән, дүртесе дә...

Кичкә таба солдат китеп барды. Ә Ана күзенә төне буе йокы кермәде, улы турында уйлап чыкты. Аның туганнан алып бар гомерен күз алдыннан үткәрде... Ә иртән, көндәге вакытында торып, мичен ягып җибәрде. Чарт - чорт килеп янган утын агачларга карап утырганда ниләр генә уйлап бетермәде ул. Әрдәнәнең читендәге утыннарны төтен урый, ә уртадагылары ялкынланып яна. Шул минутларда нәкъ ут эчендә калган танкны күз алдына китергәндәй булды ул... Менә янып торган танкның люгы ачылып китте дә, башта кул, аннан танкистның баш киеме күренде... Улы бит бу! «Әни!» дип ачы итеп кычкырган тавыш ишеткәндәй булды. Үзе дә сизмәстән «Улым!» дип ыңгырашып, хәлсезләнеп идәнгә ауды.

Тавышка балалар уянды. Алар мич алдында идәндә яткан әниләре янына йөгереп килделәр: «Әни, нәрсә булды?» Әле ярый, нәрсә булганын аңышып әниләрен салкын су бөркеп хушына китерергә башларына җитте...»

... Ул хатынның исем - фамилиясен белә алмаган идем мин. Соңыннан гына ачыкланды: Евдокия Кузьминична Крючкова булган икән ул. Дүрт улын сугышта югалткан.

# ЮЛ ҺӘМ БАЛАЛАР

**Узган ел «Росинка» балалар бакчасы «Яшел ут» республика ярышында өченче урынга чыккан иде.**

Республика күләмендәге шундый бәйгедә призлы урын яулау коллективның максатчан эшләве нәтиҗәсе булып тора. Иң мөһиме, Галина Степановна Королева җитәкчелегендәге бу коллектив ирешелгән уңышлар белән канәгатьләнмичә, бүгенге көндә дә бу юнәлештә эшне йомшартмый, чөнки педагогларның һәркайсы яхшы белә: яшьли үзләштергән күнекмәләр бала күңеленә мәңгегә кереп кала. Шуңа да коллективның балаларга яшьли юлда ориентлашырга өйрәтүләрен, юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерүгә ярдәм итүләрен ата - аналар да хуплыйлар. Ни өчен дигәндә безнең тормышыбызда автомобильнең роле үсә бара. Ә балаларда юл йөрү кагыйдәләренә дөрес мөнәсәбәт тәрбияләү аларга юллар белән бәйле проблемалардан котылырга ярдәм итәр. Аннары балалар үзләре дә юл йөрү «уеннарын» теләп, алай гына да түгел яратып уйныйлар.

Педагогия коллективы төрле өйрәтү уеннары сценарийларын эшләү һәм үткәрүгә җитди карый. Аларның барышында нинди генә ситуацияләргә юлыкмыйсың. Уеннар, конкурслар һәм викториналар өчен атрибутлар исә методист Татьяна Александровна Сарникова җитәкчелеге астында, бакча хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла. Ә балалар «Брейн ринг», «Иң яхшы җәяүле», «Тыкрык», «Лото», «Транспорт төрләре», «Юл билгеләре» дигән чараларда аеруча теләп уйныйлар. Балалар группалардагы урамнар макетларын да кызыксынып өйрәнәләр. Безнең юл йөрү хәвефсезлеге фонды бакчага уен өчен юл билгеләре комплектын бүләк итүен дә хупладылар алар.


Гомумән, педагогик коллективның бу юнәлештәге эше күпкырлы: аларның ата - аналар белән бергә үткәргән кичәләрендә өлкәннәр дә, балалар да теләп катнашалар. Группалардагы ата - аналар почмакларында балаларга юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтүдә ата - аналарның роле турында искәрмәләр дә бар.

Без, юл йөрү хәвефсезлеге сагында торучыларны, «Росинка»да шундый чаралар үткәрелүе сөендерә. Аларның тәҗрибәсе мәктәпкәчә учреждениеләрнең башкаларында да файдаланылса бик әйбәт булыр иде.

**Г.ГЫЙМАЛТДИНОВА.**


Юл хәрәкәте иминлеге фонды һәм оборона спорт - техника җәмгыятенең район Советы каршындагы

*Картинг - клуб*



9 - 12 яшьлек малайларны үзенә чакыра.

**Белешмәләр өчен тел.: 2 - 15 - 50, 2 - 25 - 80.**


## КОТЛЫЙБЫЗ!


Нәриман авылында яшәүче кадерле әтиебез, бабабыз **Наил Мостафа улы Мифтаховны** 70 еллык юбилее белән котлыйбыз.



Озын гомер бирсен ходай, дибез,
Кояш сиңа бирсен яктылык.
Балаларың гына түгел, оныкларың
Китерсеннәр иде яхшылык.

**Изге теләкләр белән барлык балаларың.**

*Иске Әмзә авылында яшәүче кадерле әтиебез **Мөнир Мөлековны** туган көне белән котлыйбыз.*



*Яшәү маягы син безнең өчен,*
*Кешелегең белән үрнәк син.*
*Мең - мең рәхмәт тәрбияңә, әти,*
*Безнең өчен һәрчак кирәк син.*

***Замир, Камил, Ришат гаиләләре.***

## БЕЛДЕРҮЛӘР РЕКЛАМА




*Матбугат - 97*

**«Сувар» газетасына арзан хакка язылу мөмкинлеге бар!**

***Хөрмәтле газета укучылар! Март аенда «Сувар» чуваш газетасына иске бәя буенча язылырга мөмкин. Әгәр дә 31 мартка кадәр язылырга өлгерсәгез, ул сезгә күпкә арзанга төшәчәк. Ашыгыгыз! Өлгерермен әле дип, соңга кала күрмәгез!***

***Алты айга язылу бәясе 21000 сум, өч айга 10500, бер айга 3500 сум.***

### Эшкә чакырабыз

**НГДУның технологик транспорт идарәсенә (УТТ) эшкә экскаватор машинисты, торба салу машинасы машинисты, автокран машинисты һәм «Д», «Е» категорияле шоферлар кирәк.**

***

### Алмаштырабыз

**Шәһәр уртасындагы ике бүлмәле фатирны һәм «Әфган» поселогында йорт нигезе салынган участокны - 3 бүлмәле фатирга.** Тел.: 5 - 26 - 34

***

### Сатабыз

**Әйбәт хәлдәге «Москвич М - 2140».** Тел.: 5 - 11 - 99.

***

**Бик әйбәт хәлдәге, 1994 елгы «Таврия».** Тел.: 5 - 27 - 95.

***

**Яңа «Урал» мотоциклы. Бәясе - килешү буенча.** Тел.: 5 - 18 - 24.

***

**ВАЗ - 2103.** Адрес: Фрунзе ур., 9.

***

### Сатып алабыз

**Умарта, корт оялары (пакетлар), инвентарь, Т - 16 тракторы сатып алам.**

Язмача хәбәр итү өчен адрес: 446818, Самара өлкәсе, Кошка районы, Рус Васильевкасы авылы, В.Чигаликскийга.

***

### Фатир эзлибез

**Бер бүлмәле фатир кирәк, кыйммәт түлим.** Тел.: 2 - 10 - 44.

***


### Белеп торыгыз!

**Күптармаклы җитештерү предприятиесе тарафыннан салкын су график буенча гына бирелү сәбәпле Норлат җылылык челтәре предприятиесе дә халыкка кайнар суны график белән генә бирергә мәҗбүр.**

**Бер үк вакытта җылылык челтәреннән (батарейлардан) суны агызырга ярамавын һәм моның системада җылылык температурасын сакларга комачаулавын да исегезгә төшерәбез.**

**«Алмалык» бакчачылык җәмгыяте идарәсе идарә вәкиленең эш урыны НГДУ укыту - курс комбинатының беренче катында («Огонек» кибете каршында) икәнлеген хәбәр итә.**

**Җәмгыять членнарын 20 апрельгә кадәр шул адрес буенча килеп, җиргә хокукка дәүләт актын рәсмиләштерергә чакырабыз.**

**Үзең белән паспорт, бакчачылык җәмгыяте членны кенәгәсен алып килергә кирәк. Ял көннәреннән кала һәр көнне иртәнге 7 дән кичке 4 кә кадәр кабул итәбез.**

Җәмгыять идарәсе.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2083 данә.